РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«21» июня 2022ел г. Альметьевск № 1235

Социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар яллаучылары өчен, шулай ук күпфатирлы торак йорт белән идарә итү ысулын сайлау һәм күпфатирлы йортлардагы торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тоту һәм ремонтлау турында карар кабул итмәгән, гомуми җыелышта халык өчен торак урыннарны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен түләү күләме турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 156 һәм 158 статьялары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне тоту кагыйдәләрен һәм күпфатирлы йортта хезмәт күрсәтүләр һәм идарә итү, тоту һәм ремонт эшләре башкарылган очракта, торак урынны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен тиешле сыйфатсыз һәм (яисә) билгеләнгән дәвамлылыктан артып китүче өзеклекләр белән үзгәртү кагыйдәләрен раслау турында» 2006 елның 13 августындагы 491 номерлы карары нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар яллаучылары өчен, шулай ук күпфатирлы торак йорт белән идарә итү ысулын сайлау һәм күпфатирлы йортлардагы торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тоту һәм ремонтлау турында карар кабул итмәгән, гомуми җыелышта халык өчен торак урыннарны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен 2022 елның 01 июленнән 2023 елның 30 июненә кадәр расларга һәм гамәлгә кертергә (1 нче кушымта).

2. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты карарларының үз көчләрен югалткан дип танырга:

Зак. № 305-2000

«Социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар яллаучылары өчен, шулай ук күпфатирлы торак йорт белән идарә итү ысулын сайлау һәм күпфатирлы йортлардагы торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тоту һәм ремонтлау турында карар кабул итмәгән, гомуми җыелышта халык өчен торак урыннарны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен 2021 елның 01 июленнән 2022 елның 30 июненә кадәр расларга һәм гамәлгә кертергә» 2021 елның 23 июнендәге 888 номерлы;

«Социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар яллаучылары өчен, шулай ук күпфатирлы торак йорт белән идарә итү ысулын сайлау һәм күпфатирлы йортлардагы торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тоту һәм ремонтлау турында карар кабул итмәгән, гомуми җыелышта халык өчен торак урыннарны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен 2021 елның 01 июленнән 2022 елның 30 июненә кадәр расларга һәм гамәлгә кертергә» 2021 елның 23 июнендәге 888 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 28 июлендәге 1079 номерлы .

3. Район Башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

4. Әлеге карар 2022 елның 1 июленнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе — А.М. Каюмов

ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ

Әлмәт муниципаль районы
Башкарма комитетының
«21» июнь 2022ел №1235
карары белән расланган
1 нче кушымта

Социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондының торак урыннарын наем шартнамәләре буенча торак урыннар яллаучылары өчен, шулай ук күпфатирлы торак йорт белән идарә итү ысулын сайлау һәм күпфатирлы йортлардагы торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тоту һәм ремонтлау турында карар кабул итмәгән, гомуми җыелышта халык өчен торак урыннарны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен 2022 елның 01 июленнән 2023 елның 30 июненә кадәр билгеләү турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләр өчен түләү күләме

| № п/п | Хезмәт күрсәтү атамасы | Үлчәү берәмлеге | Айлык тариф |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Торак фонды белән идарә итү | сум./кв. м | 2,78 |
| 2. | Гомуми файдаланудагы йорт эчендәге урыннарны җыештыру | сум/кв. м | 1,73 |
| 3. | Йорт яны территориясен җыештыру | сум/кв. м | 2,57 |
| 4. | Чүп үткәргечләргә хезмәт күрсәтү | сум/кв. м | 0,74 |
| 5. | Автомат рәвештә бикләнә торган җайланмаларсыз торак биналарны ремонтлау һәм йорт яны территориясен төзекләндерү | сум/кв. м | 2,34 |
| 6. | Автомат рәвештә бикләнә торган җайланмалары булган торак биналарны ремонтлау һәм йорт яны территориясен төзекләндерү (күпфатирлы йортта гомуми мөлкәт составында булганда) | сум/кв. м | 2,73 |
| 7. | Салкын су белән тәэмин итү приборларыннан башка йорт эчендәге инженерлык салкын су суүткәргеч-канализация челтәрләренә техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау | сум/кв. м | 2,08 |
| 8. | Салкын су белән тәэмин итү приборлары белән йорт эчендәге инженерлык салкын су суүткәргеч-канализация челтәрләренә техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау | сум/кв. м | 2,28 |
| 9. | Җылылык алмаштыру җайланмалары, салкын һәм кайнар су белән тәэмин итүне исәпкә алу приборлары белән җиһазландырылган салкын һәм кайнар су белән тәэмин итүнең йорт эчендәге суүткәргеч-канализация челтәрләренә техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау | сум/кв. м | 3,08 |
| 10. | Җылылык белән тәэмин итү җайланмалары, җылылык энергиясен исәпкә алу приборлары һәм һава торышын җайга салу төеннәре булган үзәк җылылык челтәрләрен агымдагы ремонтлау һәм карап тоту | сум/кв. м | 2,25 |
| 11. | Салкын һәм кайнар су белән тәэмин итү приборларыннан башка йорт эчендәге | сум/кв. м | 2,34 |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | инженерлык салкын һәм кайнар су сууткәргеч-канализация челтәрләренә техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау | | |
| 12. | Салкын һәм кайнар су белән тәэмин итүнең йорт эчендәге инженерлык сууткәргеч-канализация челтәрләренә салкын һәм кайнар су белән тәэмин итүне исәпкә алу приборлары белән техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау | сум/кв. м | 2,80 |
| 13. | Салкын су белән тәэмин итүне исәпкә алу приборы белән һәм кайнар су белән тәэмин итүне исәпкә алу приборыннан башка йорт эчендәге инженерлык сууткәргеч-канализация челтәрләренә техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау | сум/кв. м | 2,54 |
| 14. | Кайнар су белән тәэмин итүне исәпкә алу приборы белән һәм салкын су белән тәэмин итүне исәпкә алу приборыннан башка йорт эчендәге сууткәргеч-канализация челтәрләренә техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау | сум/кв. м | 2,60 |
| 15. | Җылылык энергиясен исәпкә алу приборларыннан һәм һава торышын җайга салу төеннәреннән башка үзәк җылылык челтәрләрен агымдагы ремонтлау һәм карап тоту | сум/кв. м | 1,44 |
| 16. | Җылылык энергиясен исәпкә алу приборлары һәм һава торышын җайга салу төеннәре булган үзәк җылылык челтәрләрен агымдагы ремонтлау һәм карап тоту | сум/кв. м | 2,14 |
| 17. | Һава торышын җайга салу төеннәреннән башка җылылык энергиясен исәпкә алу приборлары булган үзәк җылылык челтәрләрен агымдагы ремонтлау һәм карап тоту | сум/кв. м | 1,83 |
| 18. | Газ белән тәэмин итү челтәрләрен агымдагы ремонтлау һәм карап тоту | сум/кв. м | 0,20 |
| 19. | Электр белән тәэмин итү челтәрләрен агымдагы ремонтлау һәм карап тоту | сум/кв. м | 0,82 |
| 20. | Җылылык алмаштыру җайланмалары белән җиһазландырылган салкын һәм кайнар су белән тәэмин итүнең йорт эчендәге су үткәргеч-канализация челтәрләренә техник хезмәт күрсәтү һәм ремонт | сум/кв. м | 2,82 |
| 21. | Дератизация | сум/кв. м | 0,15 |
| 22. | Лифтларга техник хезмәт күрсәтү | сум/кв. м | 3,14 |
| 23. | Найм торак урыннары (яллаучылар өчен) | сум/кв. м | 6,38 |
| 24. | Контейнер мәйданчыкларын тоту | сум/кв. м | 0,11 |
| 25. | Янгын куркынычсызлыгы системаларына техник хезмәт күрсәтү һәм ремонт | сум/кв. м | 0,70 |

Район
Башкарма комитеты җитәкчесенең
икътисад буенча урынбасары А.Н. Подовалов